**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» 08 2015 № 294

Аксубаево

2016 елга муниципаль районның
һәм 2017-2018 еллар план чорына
Аксубай» бюджеты проекты раслау

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Аксубай муниципаль районы Уставы нигезендә Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең финанс һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасары Р.М. Галиев Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләре, Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы белән берлектә 2015 елның 15 ноябренә кадәр Аксубай муниципаль районы бюджеты турындагы карар проектына материаллар әзерләргә, шул исәптән:

1) 2015 елның узган чорында Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә якынча йомгаклар һәм 2015 елда социаль-икътисадый үсешнең көтелгән нәтиҗәләре;

2) Аксубай муниципаль районы бюджетының 2015елда көтелгән үтәлешен бәяләү;

3) 2016 елга һәм 2018 елга кадәрге чорга Аксубай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше фаразын,

4) 2016-2018 елларга Аксубай муниципаль районының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре проекты;

5) Аксубай муниципаль районының 2016-2018 елга эчке алынмалары программасы проекты;

6) Аксубай муниципаль районының муниципаль гарантияләр программасы проекты

7) 2016-2018 елга Аксубай муниципаль районының бюджет кредитлары бирү программасы проекты

8) бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәпләре;

9) муниципаль бурычның өске чиге турында мәгълүмат: 01.01.2016г., 31.12.2017г., 31.12.2018г., 31.12.2019г.;

10) Аксубай муниципаль районының 2016-2018нче елга берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразлау (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты);

2. 2016-2018 елларга Аксубай муниципаль районы бюджетының керемнәре һәм чыгымнары фаразын билгеләү максатларында Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасына түбәндәгеләрне тапшырырга:

1) 2015 елның 20 октябренә кадәр Аксубай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары - җирле үзидарә органнары тарафыннан Аксубай муниципаль районы бюджетына административ керемнәр керүне фаразлау;

2) Бюджетны бюджет планлаштыру субъектларына:

Аксубай муниципаль районы

2015 елның 20 октябренә кадәр - 2016-2018 елга чыгым йөкләмәләренең башлангыч реестрлары;

2015 елның 20 октябренә кадәр - 2016 елда финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән бюджет акчаларын тотуга китергән норматив хокукый актларның көчен югалткан дип тану яисә гамәлдә булуын туктатып тору турындагы тәкъдимнәр;

2015 елның 15 октябренә кадәр - Аксубай муниципаль районы бюджеты хисабыннан 2016-2018 елларда муниципаль гарантияләр алуга беренчел гаризалар;

2015 елның 25 октябренә кадәр - 2016-2018 елга Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнарының бюджет классификациясе нигезендә финанслауның иң чик күләмнәрен бүлү;

3. Аксубай муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары булган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына Аксубай муниципаль районы бюджетының финанс бюджет палатасына 2016-2018 елга Аксубай муниципаль районы бюджетына административ керемнәр фаразын төзү өчен кирәкле мәгълүматны тапшырырга;

4. Аксубай муниципаль районы бюджетының төп бүлүчеләре булган Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты бүлекләренә:

1) 2015 елның 01.10.сына кадәр социаль өлкә муниципаль учреждениеләренең сан үзгәрешләрен килештерергә;

2) 2015 елның 01.10.сына кадәр Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларында һәм ведомстволарында социаль өлкә муниципаль учреждениеләре челтәре һәм контингентлары буенча сан күрсәткечләрен килештерергә;

3) социаль өлкәдәге муниципаль учреждениеләр челтәрен арттырган очракта, Татарстан Республикасының тармак министрлыкларына һәм ведомстволарына Татарстан Республикасы башкарма органнары билгеләгән срокларда яңа муниципаль учреждениеләр ачуның максатка ярашлылыгын нигезләүне әзерләргә һәм тәкъдим итәргә.

5. Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасында:

1) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән срокларда башлангыч күрсәткечләрне 2016-2018 елга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпләү өчен килештерергә;
2) 2015 елның 25 октябренә кадәр Аксубай муниципаль районы бюджеты акчаларын баш урнаштыручыларга 2016-2018 елга финанслауның иң чик күләмнәрен җибәрергә;
3) 2015 елның 01.11.2015 елга кадәр Аксубай муниципаль районы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләр тарафыннан тапшырылган иң чик күләмнәрне бүлүне 2016-2018 елга Россия Федерациясе чыгымнарының бюджет классификациясе нигезендә финанслау күләмнәрен бүлүне карарга;
6) «2016 елга, 2017 һәм 2018 еллар план чорына Аксубай муниципаль районы бюджеты турында» карар проектын 2015 елның 15 декабренә кадәр әзерләргә;

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Галиев Р.М. һәм Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы рәисе О.П. Сетровага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А.Ф.Горбунов